**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ КИБӘХУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

**Егерменче җиденче утырыш дүртенче чакырылыш**

**18 май 2023ел** **№ 77** **Кече Кибәхуҗа ав.**

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының җирле үзидарә органнарына җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне (вәкаләтләрнең бер өлешен) тапшыру турында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советына Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәсьәләне каларга тәкъдим итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру, җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт эшчәнлеге тәртибен билгеләү, җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү өлешендә ритуаль хезмәтләр оештыру өчен шартлар тудыру буенча.

2. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Советы тарафыннан әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдим кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге башкарма комитетына:

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

әлеге карарны тормышка ашыруны тәэмин итү максатыннан, бюджет законнары нигезендә, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге Советының 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге бюджеты турында карарына үзгәрешләр кертү турында карар проектын эшләргә һәм каларга тапшырырга.

3. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Теләче муниципаль районы
Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге башлыгы И.Г.Заһидуллин